| | | |
|---|---|---|
| **МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ** |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

14.02.2014 № 70

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2014 елның 13 мартында теркәлде, №2250

**Татарстан Республикасында эшсез гражданнарга психологик ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең типовой административ регламентын раслау турында**

“Россия Федерациясендә яшәүчеләрне эш белән тәэмин итү турында” 19 апрель, 1991 ел, №1032-1 Россия Федерациясе Законы, “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 27 июль, 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон һәм “Эшсез гражданнарга социаль психологик ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең федераль дәүләт стандартын раслау турында” 09.01.2013 ел, №4н Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы нигезендә, боерык бирәм:

Татарстан Республикасында эшсез гражданнарга психологик ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең типовой административ регламентын (кушымта итеп бирелә) расларга.

**Министр** **А.Р.Шәфигуллин**

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 14.02.2014 ел, №70 боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасында эшсез гражданнарга психологик ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең типовой административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1.Татарстан Республикасында эшсез гражданнарга психологик ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең типовой административ регламенты (алга таба – Регламент) Татарстан Республикасында эшсез гражданнарга психологик ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын һәм бертигез мөмкинлеген тәэмин итү максатыннан чыгып эшләнде.

1.2. Регламент дәүләт хезмәте күрсәтү стандартын, тәртибен һәм Татарстан Республикасында яшәүчеләрне эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләренең эшсез гражданнарга психологик ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдәге вәкаләтләрен хәл итүдә гамәлләренең (административ процедуралар) эзлеклелеген билгели.

1.3. Татарстан Республикасында эшсез гражданнарга психологик ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте күрсәтү) түбәндәге максатларны тормышка ашыруга юнәлдерелгән:

эшсез гражданинның хезмәт белән кызыксынуын көчәйтү, эш эзләү һәм эшкә урнашу омтылышын арттыру, эш эзләү һәм эшкә урнашу вакытын киметү;

гражданинга һөнәри һәм социаль яктан үз урынын табуга комачаулардай психологик проблемаларны тулысынча хәл итү яки актуальлеген киметү, гамәлдәге шартларга җайлашуын арттыру, психологик халәтен яхшырту юлы белән һөнәри карьерасын тормышка ашыру.

1.4. Дәүләт хезмәте алучылар – халыкны эш белән тәэмин итү үзәге (ЦЗН) тарафыннан закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнар (алга таба – мөрәҗәгать итүчеләр).

1.5. Дәүләт хезмәте алу турында мәгълүмат тапшыру турыдан-туры ЦЗН бүлмәләрендә, шулай ук гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация чараларыннан, исәпләү техникасы һәм электрон техникадан файдалану нигезендә, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) Интернет-ресурсларында, ЦЗН, массакүләм мәгълүмат чараларында, мәгълүмати материаллар

(брошюралар, буклетлар һ.б) бастырып чыгару юлы белән хәл ителә.

1.6. ЦЗН урнашу урыны, белешмәләр алу өчен телефоннары, электрон почта адресы, дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы затлары турында мәгълүматлар бу Регламентка белешмә-кушымтада китерелә.

1.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) ЦЗН бүлмәләрендә урнашкан, дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм текстлы мәгълүматтан торган дәүләт хезмәте турында мәгълүмати стендлар аша;

2) "Интернет" челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында: **http://mtsz.tatar.ru**;

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр порталында (http:// uslugi.tatar.ru/);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (вазыйфалар) бердәм порталында (**http://www.gosuslugi.ru/**);

3) күп функцияле дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү үзәкләренә мөрәҗәгать иткәндә;

4) Министрлыкка, ЦЗН га (шәхсән яки телефон аша) телдән мөрәҗәгать иткәндә;

5) ЦЗН га язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең блок-схемасы бу Регламентка №4 кушымтада китерелгән.

Дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы органнар һәм вазыйфаи затлар турында мәгълүматлар Регламентка белешмә-кушымтада китерелгән.

1.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге законнар һәм норматив-хокукый актлар нигезендә хәл ителә:

"Россия Федерациясендә яшәүчеләрне эш белән тәэмин итү турында" 19 апрель, 1991 ел, №1032-1 Россия Федерациясе Законы (алга таба — халыкны эш белән тәэмин итү турында Закон) (Ведомости Съезда народных депутатов РСФСР и Верховного Совета РСФСР, 1991, N 18, ст. 565; Собрание законодательства Российской Федерации, 1996, N 17, ст. 1915; 1998, N 30, ст. 3613; 1999, N 18, ст. 2211; N 29, ст. 3696; N 47, ст. 5613; 2000, N 33, ст. 3348; 2001, N 53 ( 1 б.), ст. 5024; 2002, N 30, ст. 3033; 2003, N 2, ст. 160; N 2, ст. 167; 2004, N 35, ст. 3607; 2006, N 1, ст. 10; 2007, N 1 ( 1 б.), ст. 21; 2008, N 30 ( II б.), ст. 3616, N 52 ( 1 б.), ст. 6242; 2009, N 23, ст. 2761; N 30, ст. 3739; N 52 ( 1 б.), ст. 6441, ст. 6443; 2010, N 30, ст. 3993; N 31, ст. 4196; 2011, N 27, ст. 3880; N 29, ст. 4296; 2012, N 31, ст. 4322; N53, ст. 7653; 2013, N 8, ст. 717; N 27, ст. 3454, ст.3477);

"Россия Федерациясендә яшәүчеләрне социаль яклау турында" 24 ноябрь, 1995 ел, №181-ФЗ Федераль закон (Собрание законодательства Российской Федерации, 1995, № 48, ст. 4563; 1998,

№ 31, ст. 3803; 1999, № 2, ст. 232; № 29, ст. 3693; 2000, № 22, ст. 2267; 2001, № 24, ст. 2410; № 33, ст. 3426; № 53, ст. 5024; 2002, № 1, ст. 2; № 22, ст. 2026; 2003, № 2, ст. 167; № 43, ст. 4108; 2004, № 35, ст. 3607; 2005, № 1, ст. 25; 2006, № 1, ст. 10);

"Мәгълүмат, мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүматны саклау турында" 27 июль, 2006 ел, №149-ФЗ Федераль закон (Собрание законодательства Российской Федерации, 2006, № 31 (1 б.), ст. 3448; 2010, № 31, ст.4196; 2011, № 15, ст.2038; № 30 (1 б.), ст.4600);

"Персональ мәгълүматлар турында" 27 июль, 2006 ел, №152-ФЗ Федераль закон (Собрание законодательства Российской Федерации, 2006, N 31 (1 б.), ст. 3451; 2009, N 48, ст. 5716; N 52, ст. 6439; 2010, N 27, ст. 3407; N 31, ст. 4173; N 31, ст. 4196; N 49, ст. 6409; N 52, ст. 6974; 2011, N 23, ст. 3263; N 31, ст. 4701; 2013, N 14, ст. 1651; N 30, ст. 4038);

"Вәкаләтләр чикләрен билгеләүне камилләштерүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым законнар актларына үзгәрешләр кертү турында" 29 декабрь, 2006 ел, №258-ФЗ Федераль закон (30.11.2011 елгы ред.) (Собрание законодательства Российской Федерации, 2007, N 1 ( 1 б.), ст. 21) ( 01.02.2012 елдан кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән); 2007, N 17, ст. 1932; N 17, ст. 1933; N 43, ст. 5084; N 49, ст. 6070; N 30, ст. 3597; 2009, N 30, ст. 3735; N 52, ст. 6441; 2010, N 19, ст. 2291; N 31, ст. 4167; N 31, ст. 4206; N 46, ст. 5918; N 49, ст. 6409; N 49, ст. 6422; N 1, ст. 32; 2011, N 30, ст. 4590; N 47, ст. 6608; N 48, ст. 6724; N 48, ст. 6732; N 49, ст. 7039; 2012, N 30, ст. 4176; N 53, ст. 7596; N 53, ст. 7598);

"Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат белән танышу мөмкинлеген тәэмин итү хакында" 9 февраль, 2009 ел, №8-ФЗ Федераль закон (Собрание законодательства Российской Федерации, 2009, № 7, ст.776);

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 27 июль, 2010 ел, №210-ФЗ Федераль закон (алга таба - N 210-ФЗ Федераль закон) (Собрание законодательства Российской Федерации, 2010, N 31, ст. 4179;2011, N 15, ст. 2038; N 27, ст. 3873; N 27, ст. 3880; N 29, ст. 4291; N 30, ст. 4587; N 49, ст. 7061; 2012, N 31, ст. 4322; 2013, N 14, ст. 1651; N 27, ст. 3477; N 27, ст. 3480; N 30, ст. 4084);

"Электрон имза турында" 6 апрель, 2011 ел, №63-ФЗ Федераль закон (алга таба - N 63-ФЗ Федераль закон) (Собрание законодательства Российской Федерации, 2011, N 15, ст. 2036; N 27, ст. 3880; 2011, N 27, ст. 3880; N 29, ст. 3988; N 14, ст. 1668; N 27, ст. 3463; N 27, ст. 3477);

"Дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр күрсәтүне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында" 5 апрель, 2013 ел, №44-ФЗ Федераль закон (Собрание законодательства Российской Федерации 08.04.2013, № 14, ст. 1652);

30 декабрь, 2001 ел, № 197-ФЗ Россия Федерациясе Хезмәт кодексы (Собрание законодательства Российской Федерации, 2002, N 1, ст. 3; N 30, ст. 3014; N 30, ст. 3033; 2003, N 27, ст. 2700; 2004, N 18, ст. 1690; N 35, ст. 3607; 2005, N 1, ст. 27; N 13, ст. 1209; N 19, ст. 1752; 2006, N 27, ст. 2878; N 41, ст. 4285; N 52 (1 б..), ст. 5498; 2007, N 1 ( 1 б.), ст. 34; N 17, ст. 1930; N 30, ст. 3808; ст. 41, ст. 4844; N 43, ст. 5084; N 49, ст. 6070; 2008, N 9, ст. 812; N 30, ст. 3613, 3616; N 52, ст. 6235, 6236; 2009, N 1, ст. 17, 21; N 19, ст. 2270; N 29, ст. 3604; N 30, ст. 3732, 3739; N 46, ст. 5419; N 48, ст. 5717; 2010, N 31, ст. 4196; N 52 (1 б.) ст. 7002; 2011, N 1, ст. 49; N 25, ст. 3539; N 27, ст. 3880; N 30, ст. 4586, 4590, 4591, 4596; N 45, ст. 6333, 6335; N 48, ст. 6730, 6735; N 49, ст. 7015, 7031; N 50, ст. 7359; 2012, N 10, ст. 1164; N 14, ст. 1553; N 18, ст. 2127; N 31, ст. 4325; N 47, ст. 6399; N 50, ст. 6954, 6957, 6959; N 53, ст. 7605; 2013, N 14, ст. 1666, 1668; N 19, ст. 2322, 2326, 2329; N 23, ст. 2866, 2883; N 27, ст. 3449, 3454, 3477; N 30, ст. 4037);

"Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү буенча Федераль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында" 30 июнь, 2004 ел, №324 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (Собрание законодательства Российской Федерации, 2004, № 28, ст. 2901; 2007, № 37, ст.4455; 2008, № 46, ст.5337; 2009, № 1, ст.146; № 6, ст.738; № 33, ст.4081; 2010, № 26, ст.3350; 2011, № 14, ст.1935);

"Персональ мәгълүматларны персональ мәгълүматларның мәгълүмати системасында эшкәрткәндә иминлеген тәэмин итү турында нигезләмәне раслау хакында" 17 ноябрь, 2007 ел, №781 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (Собрание законодательства Российской Федерации, 2007, № 48 (II б.), 6001);

"Дәүләт вазыйфаларын үтәүнең административ регламентларын һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау турында" 16 май, 2011 ел, №373 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары ("Дәүләт вазыйфаларын үтәүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау кагыйдәләре", "Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау кагыйдәләре", "Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентлары проектларына экспертиза үткәрү кагыйдәләре" белән бергә (Собрание законодательства Российской Федерации, 2011, N 22, ст. 3169);

"Халыкны эш белән тәэмин итү һәм эшсез гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү чараларын финанслау тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында" 29 июль, 2005 ел, №485 Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгы боерыгы ( Россия Федерациясе Юстиция министрлыгында 2005 елның 20 сентябрендә теркәлгән, N 7029; боерык "Российская газета" ның 8 ноябрь, 2006 ел, N 250 санында, "Бюллетень нормативных актов федеральных органов исполнительной власти" 6 ноябрь, 2006 ел, N 45 санында басылып

чыккан);

«Эшсез гражданнарга психологик ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 27.11.2007 ел, №726 Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы белән расланган Эшсез гражданнарга психологик ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгында 2007 елның 13 декабрендә теркәлгән, №10687) (алга таба – Регламент № 726; боерык Бюллетень нормативных актов федеральных органов исполнительной власти» 28 гыйнвар, N 4 санында басылып чыккан);

«Федераль дәүләт медицина-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан бирелә торган инвалидны реабилитацияләүнең индивидуаль программасы, инвалид баланы реабилитацияләүнең индивидуаль программасы формаларын раслау турында” 04.08.2008, № 379н Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгы боерыгы ( Россия Федерациясе Юстиция министрлыгында 27.08.2008 елда теркәлгән, № 12189, 31.03.2009 елда теркәлгән, № 13625; боерык "Российская газета" ның 10 сентябрь, 2008 ел, № 190 санында басылып чыккан);

«Эшсез гражданнарга социаль психологик ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең федераль дәүләт стандартын раслау турында” 09.01.2013 № 4н Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль үсеш министрлыгы боерыгы белән расланган Эшсез гражданнарга социаль психологик ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты ( Россия Федерациясе Юстиция министрлыгында 2013 елның 28 маенда теркәлгән, № 28544; боерык "Российская газета" ның 13 июнь, 2013 ел, № 125 санында басылып чыккан) (алга таба – № 4н стандарт);

“Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре” 15.08.2007, № 388 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты **карары** (Сборник постановлений и распоряжений Кабинета Министров Республики Татарстан и нормативных актов республиканских органов исполнительной власти, 2007, N 33, ст. 1178; N 37, ст. 1400; N 4, ст. 0153; 2008, N 8, ст. 0280; N 12, ст. 0480; N 24, ст. 0930 – үз көчен югалткан; N 32, ст. 1200; N 44, ст. 1833; 2009, N 13, ст. 0508; N 25-26, ст. 1043; 2010, N 18, ст. 0691; N 45, ст. 2048; N 1-2, ст. 0043; N 11, ст. 0351; N 5, ст. 0204; N 19, ст. 0754; 2011, N 27, ст. 1234; N 40, ст. 2034; N 47, ст. 2483; N 4, ст. 0118; N 9, ст. 0325; 2012, N 35-36, ст. 1117; N 52, ст. 1772; N 70, ст. 2345; N 80, ст. 2661; 2013, N 41, ст. 1279; N 62, ст. 1947; 22 август, 2013 ел,N 592 ТР МК карары – карар рәсми төстә басылып чыкмады);

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма

органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 02.11.2010, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты **карары** (Сборник постановлений и распоряжений Кабинета Министров Республики Татарстан и нормативных актов республиканских органов исполнительной власти, 2010, N 46, ст. 2144; 2011, N 48, ст. 2612; 2012, N 40, ст. 1252).

1.11. Бу Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

административ регламент – Татарстан Республикасында эшсез гражданнарга психологик ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен билгеләүче норматив-хокукый акт;

Татарстан Республикасында яшәүчеләрне эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәте – Татарстан Республикасында яшүчеләрне эш белән тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында билгеләнгән вәкаләтләре чикләрендә мөрәҗәгать итүчеләр запрослары буенча эшчәнлеге;

мөрәҗәгать итүче – ЦЗН тарафыннан закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылып, телдән, язмача яки электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү турында запрос белән Татарстан Республикасында яшәүчеләрне эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесенә мөрәҗәгать иткән физик зат;

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен бозуга шикаять (алга таба — шикаять) – мөрәҗәгать итүченең ЦЗН да яки ЦЗН белгече тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү процессында санга сугылмаган хокукларын яки законлы мәнфәгатьләрен торгызу яки яклау турында таләбе.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләп атамасы | Стандартка карата таләп эчтәлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив–хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте атамасы | Эшсез гражданнарга психологик ярдәм | Халыкны эш белән тәэмин итү турында Законның 7.1.-1 ст. 1 өлеше, 8 п |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче орган (учреждение) атамасы | Халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт казна учреждениесе (алга таба – ЦЗН).<br>ЦЗН Татарстан Республикасы тиешле муниципаль берәмлекләр территорияләрендә дәүләт хезмәте күрсәтүне тәэмин итә.<br>ЦЗН тарафыннан килешү нигезендә җәлеп ителгән, кирәкле белем һәм эш тәҗрибәсенә, психологик ярдәм күнекмәләренә ия булып, эшсез кешедә хезмәт белән кызыксынуны тудыру, эш эзләү теләген көчәйтү, психологик халәтен яхшырту һәм (яки) ысулларын белгән белгечләр, Россия Федерациясе законы нигезендә тиешле хезмәтләр күрсәтүгә хокуклы оешмалар дәүләт хезмәтенең бер өлешен күрсәтә ала. | № 4н стандартның 11 п. |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Мөрәҗәгать итүчегә тәкъдимнәрдән торган дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмә бирү (№ 3 кушымта). | № 4н стандартның 17 п. |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга | Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен рөхсәт ителә торган максималь вакыт:<br>дәүләт хезмәтен индивидуаль күрсәткәндә - | № 59-ФЗ Федераль закон;<br>№ 4н стандартның 16 п.; |

| | | |
|---|---|---|
| мөрәҗәгать итү зарурилыгыннан чыгып | мөрәҗәгать итүченең тест (анкета) үтү вакытын кертмичә, 90 минуттан артмаска тиеш;<br>дәүләт хезмәтен төркемләп күрсәткәндә - мөрәҗәгать итүченең тест (анкета) үтү вакытын кертмичә, 4 сәгатьтән артмаска тиеш.<br>Гражданнар дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күп функцияле үзәкләренә мөрәҗәгать иткәндә, (алга таба – МФЦ) ЦЗНга гариза тапшыру МФЦ белән ЦЗН арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда тәэмин ителә, әмма гаризаны МФЦда теркәгәннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен халыкны – физик затларны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре алучылар регистры урын алган программ-техник комплекста теркәү белән бәйле административ процедураларны хәл итүнең рөхсәт ителгән максималь срогы 20 минуттан артмаска тиеш.<br>Гражданинның мөрәҗәгать итү датасын һәм вакытын алдан килештереп кую очрагында дәүләт хезмәте күрсәтелүне көтү вакыты 5 минуттан артмаска тиеш.<br>Электрон почта, факсимиль элемтә чараларыннан файдаланып җибәрелгән мөрәҗәгатьне кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча язмача | № 726 регламентның 32 п.;<br>№ 726 регламентның 30 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | мөрәҗәгатькә җавап әзерләү срогы мөрәҗәгать теркәүгә алынганнан соң 30 календарь көненнән дә артмаска тиеш. | |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләрне күрсәтү өчен закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә мөрәҗәгать итүче тапшырырга тиешле кирәкле документларның тулы исемлеге, мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәтләрен алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны күрсәтү тәртибе | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – Гариза) (№ 1 кушымта).<br>Россия Федерациясе гражданины паспорты яки аны алыштыручы документ; чит ил гражданины, гражданлыксыз зат шәхесен раслаучы документ.<br>Билгеләнгән тәртиптә бирелеп, хезмәтнең тәкъдим ителә торган характеры һәм шартлары турында бәяләмәдән торган инвалидны реабилитацияләүнең индивидуаль программасы (инвалидлар категориясенә керүче гражданнар өчен) | № 4н стандартның 5,13 п.п. |
| 2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булып, мөрәҗәгать итүче тапшыруга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан дәүләт хезмәтләрен алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны күрсәтү тәртибе; документларны үз | Әлеге категориягә кертелергә мөмкин булган документлар тапшыру таләп ителми. | |

| | | |
|---|---|---|
| карамагында тоткан дәүләт органы, җирле үзидарә органы яки оешма атамасы | | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив-хокукый актларда күздә тотылган очракларда килештерергә тиешле (дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы хәл итә) дәүләт хакимияте органнары (җирле үзидарә органнары) һәм аларның структур подразделениеләре исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең тулы исемлеге | Документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләр күздә тотылмаган. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып торуга нигезләр күздә тотылмаган.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартуга нигезләр булып тора:<br>а) мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе гражданины паспортын яки аны алыштыручы документны (Россия Федерациясе гражданины өчен), чит ил гражданины шәхесен һәм гражданлыгын | №726 регламентның 14–16 п.п. |

| | | |
|---|---|---|
| | раслаучы документлар (чит ил гражданнары өчен), гражданлыксыз зат шәхесен раслаучы документлар (гражданлыксыз затлар өчен) тапшырмавы;<br>б) билгеләнгән тәртиптә бирелә торган инвалидны реабилитацияләүнең индивидуаль программасын күрсәтмәү (инвалидлар категориясенә керүче мөрәҗәгать итүчеләр өчен). | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә. | № 210-ФЗ Федераль Законның 8 ст.;<br>Халыкны эш белән тәэмин итү турында Законның 15 ст. 3 п.;<br>№ 4н стандартның 12 п. |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләргә түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында запрос тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Алдан язылып кую очрагында дәүләт хезмәте күрсәтелүне көтүнең максималь срогы 5 минуттан артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең рөхсәт ителә торган максималь срогы:<br>дәүләт хезмәтен индивидуаль күрсәткәндә– мөрәҗәгать итүченең тест (анкета) узу вакытын | № 4н стандартның 8 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | кертмичә, 90 минуттан артмаска тиеш;<br>дәүләт хезмәтен төркемләп күрсәткәндә– мөрәҗәгать итүченең тест (анкета) узу вакытын кертмичә, 4 сәгатьтән артмаска тиеш. | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында, шул исәптән электрон рәвештә, запросын теркәү срогы | Гариза ЦЗНга кергәннән соң бер көн эчендә. | № 4н стандартның 6,7,18 п.п. |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм кабул итү урынына, мондый хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыруга карата таләпләр | Дәүләт хезмәте тиешле күрсәткечләр белән тәэмин ителгән бүлмәләрдә күрсәтелә. Дәүләт хезмәте алучыларны кабул итү бу максатлар өчен махсус билгеләнелгән бүлмәләрдә (кабинетлар) хәл ителә. Кабул итү урыннары тәэмин ителгән:<br>янгын сүндерү системасы;<br>мәгълүмати стендлар;<br>документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар белән.<br>Белгечләрнең эш урыннары, фамилиясен, исемен, атасының исемен, вазыйфасын күрсәтеп, стенада элмә такталар яки өстәл табличкалары белән тәэмин ителгән. | № 726 регламентның 41–45 п.п. |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең дәүләт хезмәте алучылар өчен мөмкинлеге һәм сыйфат күрсәткечләре | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлек күрсәткечләре булып тора:<br>1) биналарның җәмәгать транспорты йөри торган зонада урнашкан булуы; | |

| | | |
|---|---|---|
| | 2) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле санда белгечләрнең булуы;<br>3) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гаризаны электрон рәвештә язып тапшыру мөмкинлеге булуы;<br>4) мәгълүмати стендларда, “Интернет”челтәрендәге мәгълүмати ресурсларда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары һәм сроклары турында тулы мәгълүматның булуы.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып тора:<br>1) документларны кабул итү һәм карап тикшерү срокларын үтәү;<br>2) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу срогын үтәү;<br>3) дәүләт хезмәткәрләренең Регламентны бозу очраклары (нигезле шикаятьләр) булу-булмау (шундый очракларның, шикаятьләрнең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы ЦЗН вазыйфаи затларының гомуми санына карата нисбәте).<br>МФЦда дәүләт хезмәте күрсәтү очрагында документларны кабул итү һәм бирүне МФЦ белгече хәл итә. | |
| 2.16. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре. | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында запрос электрон рәвештә “Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы” республика | № 4н стандартның 18 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | дәүләт мәгълүмат системасы (http//uslugi.tatar.ru) аша җибәрелергә мөмкин.<br>ЦЗНга гариза-анкета, №63-ФЗ Федераль закон һәм №210-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә мөрәҗәгать итүченең электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәрелергә мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте электрон рәвештә күрсәтелми. | |

**3. Административ процедураларның (гамәлләр) составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары, аларны башкару тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон рәвештә административ процедураларны (гамәлләр) үтәү үзенчәлекләре**

3.1. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт ярдәме, билгеләнгән тәртиптә расланган график нигезендә, индивидуаль рәвештә һәм (яки) төркемләп күрсәтелергә мөмкин.

3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны (гамәлләр) үз эченә ала.

1) халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре алучылар регистрында мөрәҗәгать итүче турында мәгълүматлар;

2) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе, аны күрсәтү формалары һәм графигы, психологик ярдәм юнәлешләре турында мәгълүмат җиткерү (консультация бирү);

3) мөрәҗәгать итүчегә эшсез гражданнарга психологик ярдәм күрсәткәндә файдаланыла торган методикалар буенча тест (анкета) тест ысулын сайлап алуны, (тиешле программадан файдаланып яки язмача рәвештә (тестлар, анкеталар бланклары тутыру юлы белән) һәм дәүләт хезмәте күрсәтү формасын (төркемләп яки индивидуаль) тәкъдим итү;

4) мөрәҗәгать итүче сайлап алган үткәрү формасыннан чыгып, методикалар буенча тест (анкета) үткәрү;

5) мөрәҗәгать итүченең тест (анкета) материалларын эшкәртү;

6) мөрәҗәгать итүче белән тест (анкета) нәтиҗәләре буенча фикер алышу һәм эшкә урнашуга, һөнәри һәм карьера үсешенә комачаулардай төп проблемаларны ачыклау;

7)мөрәҗәгать итүче белән психологик ярдәм юнәлешләрен килештерү, психологик консультация бирү һәм (яки) психологик тренингны кертеп, мөрәҗәгать итүченең ачыкланган проблемаларыннан, индивидуаль үзенчәлекләреннән һәм тормыш эшчәнлегендәге чикләүләрдән һәм аның тарафыннан сайлап алынган дәүләт хезмәте күрсәтү формасыннан чыгып;

8) мөрәҗәгать итүче белән тренинг дәресләре үткәрү (эшсез гражданин ризалыгы белән видеотренинг) һәм (яки) психоэмоциональ киеренкелекне һәм борчылу халәтен юкка чыгаруга, эш эзләү процессында килеп чыгучы авырлыкларга карата уңай мөнәсәбәт булдыру, төрле низаглы хәлләр килеп туганда үзенең проблемасын һәм үзенең ролен киңрәк аңлавын булдыру, үз-үзен тотышының яңа ысулларына өйрәтү, үз-үзен тотышында тискәре факторларны бетерүгә юнәлдерелгән психологик консультацияләр уздыру;

9) тренинг дәресләре һәм (яки) психологик консультацияләр нәтиҗәләре буенча фикер алышу;

10) хезмәт белән кызыксынуны көчәйтү, эш эзләү һәм эшкә урнашу буенча омтылышны көчәйтү, һөнәри һәм социаль яктан үз урынын табуга комачаулаган психологик проблемаларны хәл итү яки актуальлеген киметү, чынбарлыктагы шартларга җайлашуны көчәйтү, психологик халәтне оптимальләштерү юлы

белән һөнәри карьераны тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмә рәвешендә тәкъдимнәр әзерләү;

11) мөрәҗәгать итүче белән тәкъдимнәр буенча фикер алышу һәм аларны тормышка ашыру буенча эшсез гражданин белән гамәлләр юнәлешен билгеләү;

12) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмә бирү, дәүләт хезмәте күрсәтү турында белешмәнең икенче нөсхәсен дәүләт хезмәтләре алучының личное делосына урнаштырып кую;

13) административ процедураларны (гамәлләр) үтәү нәтиҗәләрен халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре алучылар регистрына кертү;

Бу Регламентның 3.2 пунктындагы 3–5, 7–13 абзацларында күздә тотылган административ процедураларны (гамәлләр) дәүләт хезмәтен төркемләп күрсәтү формасында хәл итәргә ярый.

3.3. Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре алучылар регистрында мөрәҗәгать итүче турында мәгълүматларга анализ.

ЦЗН белгече:

хезмәт күрсәтү алуга гариза (№1 кушымта) (кирәк булган очракта гариза тутыруга ярдәм итә) кабул итә, яки ЦЗН тарафыннан бирелгән психологик ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим (№2 кушымта) урын алган ризалыкны рәсмиләштерә.

Гариза ЦЗНга почта аша, факсимиль элемтә яки электрон рәвештә, шул исәптән Бердәм порталдан яки республика порталыннан файдалану нигезендә җибәрелгәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен алдан язылып кую мөмкинлеге тәэмин ителә. Мөрәҗәгать итүчеләр белән ЦЗНга мөрәҗәгать итү датасын һәм вакытын килештерү телефон яки электрон элемтә чараларыннан, Интернет челтәрен кертеп, почта элемтәсеннән файдалану нигезендә, гариза ЦЗНда теркәүгә алынганнан соң килгән эш көненнән дә соңга калмыйча хәл ителә;

халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре алучылар регистры урын алган программ–техник комплекста дәүләт хезмәте алучы турында мәгълүматларны эзли һәм электрон рәвештә тиешле учет документлары бланкларын эзләп таба;

мөрәҗәгать итүченең халыкны эш белән тәэмин итү үзәгендә эшсез сыйфатында тору–тормавын, мөрәҗәгать итүченең инвалидлар категориясенә керү–кермәвен билгели,

ЦЗНның агымдагы архивыннан мөрәҗәгать итүченең личное делосын (булган очракта) ала.

ЦЗН белгече, Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән нигезләрнең булуы сәбәпле дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту очрагында, баш тарту сәбәпләрен, нигезләрен, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен аңлата, язмача рәвештә карар рәсмиләштерә һәм аны мөрәҗәгать итүчегә бирә.

Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән баш тартуга нигезләр булган очракта, ЦЗН белгече мөрәҗәгать итүче белән язмача яки телдән дәүләт хезмәте күрсәтүнең күздә тотылган датасын һәм вакытын килештерә.

Башкару срогы: процедура мөрәҗәгать кергәннән соң 5 минут эчендә хәл

ителә; дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту очрагында – 15 минут эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: бу Регламентта билгеләнгән нигезләр буенча дәүләт хезмәте күрсәтү яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар, дәүләт хезмәте күрсәтү датасын һәм вакытын билгеләү.

3.4. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе, аны күрсәтү формалары һәм графигы, психологик ярдәм юнәлешләре турында мәгълүмат җиткерү (консультация бирү).

ЦЗН белгече:

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе, психологик ярдәм юнәлешләре, эшсез гражданнарга психологик ярдәм итүдә кулланыла торган ысуллар, методикалар, тренинг формалары һәм технологияләр турында консультация бирә;

дәүләт хезмәте күрсәтү процедурасы турында консультация бирә;

мөрәҗәгать итүчегә кирәкле документлар тутыруга ярдәм итә.

Башкару срогы: дәүләт хезмәтен индивидуаль күрсәтү процедурасы, мөрәҗәгать итүче билгеләнгән көнне килгәндә, 5 минут эчендә, төркемләп күрсәтү – процедура башланганнан соң 10 минут эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтү турында консультация бирү.

3.5. Мөрәҗәгать итүчегә эшсез гражданнарга психологик ярдәм итү буенча кулланыла торган методикалар нигезендә тест (анкета), тест ысулын (тиешле программадан файдаланып яки язмача рәвештә (тестлар, анкеталар бланкларын тутыру юлы белән) һәм дәүләт хезмәте күрсәтү рәвешен (төркемләп яки индивидуаль) сайлап алуны тәкъдим итү.

ЦЗН белгече:

мөрәҗәгать итүченең кулай эш эзләүдәге, эшкә урнашудагы кыенлыклары сәбәпләрен, шулай ук һөнәрдә үз урынын табуга һәм карьера үсешенә комачаулап килгән психологик, шәхсән һәм һөнәри проблемаларын ачыклый;

мөрәҗәгать итүченең кулай эш эзләүдә һәм эшкә урнашуда кыенлыклар кичерү сәбәпләрен ачыклау йомгаклары буенча мөрәҗәгать итүче белән әңгәмә уздыра,

психологик ярдәм юнәлешләрен аныклау өчен мөрәҗәгать итүчегә эшсез гражданнарга психологик ярдәм итүдә кулланыла торган, нәтиҗәлелек, ышанычлылык, дифференциацияләнгәнлек, фараз (мәгълүмати) кыйммәте критерийларыннан, валидлык дәрәҗәсеннән, кулланыла торган башка методлар, методикалар, һәм тренинглар белән бергә куллану мөмкинлекләреннән, мәгълүматларны тикшерү һәм эшкәртү стандартларына туры килүеннән, мәгълүматларны эшкәртү һәм нәтиҗәләргә ирешү өчен вакыт чыгымнары оптимальлегеннән чыгып сайлап алынган методикалар буенча тест (анкета) узуны тәкъдим итә;

мөрәҗәгать итүчегә тиешле программ-техник комплекстан һәм махсус җиһаздан файдалану нигезендә яки гадәти язмача рәвештә (тестлар, анкеталар бланкларын тутыру юлы белән) тест (анкета) узу формасын сайлап алуны

тәкъдим итә.

Башкару срогы: дәүләт хезмәтен индивидуаль күрсәтү процедурасы, мөрәҗәгать итүче билгеләнгән көнне килгәндә, 5 минут эчендә, төркемләп күрсәтү – процедура башланганнан соң 10 минут эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүченең тест (анкета) узуга ризалык бирүе (баш тарту), ризалык бирү очрагында – тест (анкета) үткәрү формасын билгеләү.

3.6. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан сайлап алынган тест (анкета) узу формасыннан чыгып, тест (анкета) үткәрү.

ЦЗН белгече мөрәҗәгать итүчегә үзе сайлап алган форма буенча тест уздыра.

Башкару срогы: дәүләт хезмәтен индивидуаль күрсәтү процедурасы, мөрәҗәгать итүче билгеләнгән көнне килгәндә, күп дигәндә 40 минут эчендә, төркемләп күрсәтү – 60 минут эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: тест (анкета) үткәрү.

3.7. Мөрәҗәгать итүченең тест (анкета) материалларын эшкәртү

ЦЗН белгече:

мөрәҗәгать итүченең тест (анкета) материалларын кулланылыштагы методикалар нигезендә эшкәртә;

тест (анкета) нәтиҗәләрен анализлый;

мөрәҗәгать итүче белән әңгәмә һәм тест (анкета) нәтиҗәләре буенча психологик диагностика уздыра, мөрәҗәгать итүченең эшкә урнашуына комачаулардай төп проблемаларны ачыклый.

Башкару срогы: процедура алдагы процедура тәгалләнгәннән соң 10 минут эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: уздырылган тест (анкета) буенча бәяләмә.

3.8. Мөрәҗәгать итүче белән тест (анкета) нәтиҗәләре буенча фикер алышу һәм эшкә урнашуга, һөнәрдә үз урынын табуга һәм карьера үсешенә комачаулый торган төп проблемаларны ачыклау.

ЦЗН белгече мөрәҗәгать итүчене тест (анкета), психологик диагностика нәтиҗәләре, мөрәҗәгать итүченең эшкә урнашуына комачаулык итә торган төп проблемалары (ачыкланган) белән таныштыра.

Башкару срогы: дәүләт хезмәтен индивидуаль күрсәтү процедурасы, мөрәҗәгать итүче билгеләнгән көнне килгәндә, 5 минут эчендә, төркемләп күрсәтү – 10 минут эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүче белән тест (анкета) нәтиҗәләре турында фикер алышу.

3.9. Мөрәҗәгать итүченең ачыкланган проблемаларыннан, индивидуаль үзенчәлекләреннән һәм тормыш эшчәнлегендәге чикләнүләрдән, үзе сайлап алган дәүләт хезмәте күрсәтү формасыннан чыгып, мөрәҗәгать итүче белән психологик ярдәм юнәлешләрен, психологик консультация һәм (яки) психологик тренингны кертеп, килештерү.

ЦЗН белгече:

мөрәҗәгать итүчегә психологик ярдәм юнәлешләрен билгели, психологик консультацияне, психологик тренинг һәм психологик коррекцияне кертеп;

мөрәҗәгать итүче белән психологик консультация үткәрә;

мөрәҗәгать итүчене үзенә эшкә урнашуга комачаулый торган проблемаларны, эмоциональ, когнитив, кызыксыну характерындагы, үз-үзен тотышындагы проблемаларны кертеп, хәл итүдә файдаланып булырдай психологик коррекция ысуллары һәм методикалары белән таныштыра.

Башкару срогы: дәүләт хезмәтен индивидуаль күрсәтү процедурасы, мөрәҗәгать итүче билгеләнгән көнне килгәндә, 5 минут эчендә, төркемләп күрсәтү –10 минут эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчене психологик коррекция ысуллары белән таныштыру һәм килештерү.

3.10. Мөрәҗәгать итүче белән тренинг дәресләре (эшсез гражданин ризалыгы белән видеотренинг) һәм (яки) психоэмоциональ киеренкелекне һәм борчылу халәтен юкка чыгаруга, эш эзләү процессында килеп чыгучы авырлыкларга карата уңай мөнәсәбәт булдыру, төрле низаглы хәлләр килеп туганда үзенең проблемасын һәм үзенең ролен киңрәк аңлавын булдыру, үз-үзен тотышының яңа ысулларына өйрәтү, үз-үзен тотышында тискәре факторларны бетерүгә юнәлдерелгән психологик консультацияләр үткәрү.

ЦЗН белгече мөрәҗәгать итүче белән мөрәҗәгать итүченең эшкә урнашуына комачаулый торган проблемаларны, борчылу халәтен, психологик киеренкелекне юкка чыгаруны, кертеп, хәл итүгә, уй–хисләрен иркен төстә белдерүгә, кичерешләренә бәйле рәвештә үз проблемаларын аңлау һәм ачып салуга, эмоциональ ярдәм күрсәтү һәм алуга, кичерешләрен һәм уй-фикерләрен уңай якка боруга, төрле низаглы хәлләр килеп туганда үзенең проблемасын һәм үзенең ролен киңрәк аңлавын булдыруга, үз-үзен тотышының яңа ысулларына өйрәтүгә, үз-үзен тотышында тискәре факторларны бетерүгә, нәтиҗәле аралашу күнекмәләрен үстерүгә, башка шәхсән һәм һөнәри үзенчәлекләрен көйләүгә юнәлдерелгән психологик тренинг үткәрә.

Башкару срогы: дәүләт хезмәтен индивидуаль күрсәтү процедурасы, мөрәҗәгать итүче билгеләнгән көнне килгәндә, 25 минут эчендә, төркемләп күрсәтү –130 минут эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: тренинг дәресе һәм (яки) психологик консультация үткәрү.

3.11. Тренинг дәресләре һәм (яки) психологик консультация буенча фикер алышу

ЦЗН белгече мөрәҗәгать итүчене үткәрелгән тренинг дәресләре һәм (яки) психологик консультация нәтиҗәләре, мөрәҗәгать итүченең эшкә урнашуына комачаулый торган төп проблемалар (ачыкланган) белән таныштыра.

Башкару срогы: дәүләт хезмәтен индивидуаль күрсәтү процедурасы, мөрәҗәгать итүче билгеләнгән көнне килгәндә, 5 минут эчендә, төркемләп күрсәтү –10 минут эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүче белән үткәрелгән тренинг дәресләре һәм (яки) психологик консультация нәтиҗәләре буенча фикер алышу.

3.12. Хезмәт белән кызыксынуны көчәйтү, эш эзләү һәм эшкә урнашу буенча омтылышны көчәйтү, һөнәри һәм социаль яктан үз урынын табуга комачаулаган психологик проблемаларны хәл итү яки актуальлеген киметү, чынбарлыктагы шартларга җайлашуны көчәйтү, психологик халәтне оптимальләштерү юлы белән һөнәри карьераны тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмә рәвешендә тәкъдимнәр әзерләү.

ЦЗН белгече хезмәт белән кызыксынуны көчәйтү, эш эзләү һәм эшкә урнашу буенча омтылышны көчәйтү, һөнәри һәм социаль яктан үз урынын табуга комачаулаган психологик проблемаларны хәл итү яки актуальлеген киметү, чынбарлыктагы шартларга җайлашуны көчәйтү, психологик халәтне оптимальләштерү юлы белән һөнәри карьераны тормышка ашыру буенча тәкъдимнәр әзерли.

Башкару срогы: дәүләт хезмәтен индивидуаль күрсәтү процедурасы, мөрәҗәгать итүче билгеләнгән көнне килгәндә, 10 минут эчендә, төркемләп күрсәтү –15 минут эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: хезмәт белән кызыксынуны көчәйтү, эш эзләү һәм эшкә урнашу буенча омтылышны көчәйтү буенча тәкъдимнәрне рәсмиләштерү.

3.13. Мөрәҗәгать итүче белән тәкъдимнәр буенча фикер алышу һәм аларны тормышка ашыру буенча эшсез гражданин гамәлләре юнәлешләрен билгеләү.

ЦЗН белгече хезмәт белән кызыксынуны көчәйтү, эш эзләү һәм эшкә урнашу буенча омтылышны көчәйтү, һөнәри һәм социаль яктан үз урынын табуга комачаулаган психологик проблемаларны хәл итү яки актуальлеген киметү, чынбарлыктагы шартларга җайлашуны көчәйтү, психологик халәтне оптимальләштерү юлы белән һөнәри карьераны тормышка ашыру буенча тәкъдимнәр ягыннан мөрәҗәгать итүче белән фикер алышу үткәрә.

Башкару срогы: дәүләт хезмәтен индивидуаль күрсәтү процедурасы, мөрәҗәгать итүче билгеләнгән көнне килгәндә, 5 минут эчендә, төркемләп күрсәтү –15 минут эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүче белән тәкъдимнәр буенча фикер алышу.

3.14. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмә бирү, дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмәнең икенче нөсхәсен дәүләт хезмәтләре алучының личное делосына урнаштырып кую.

ЦЗН белгече бу Регламентка №3 кушымта нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында ике нөсхәдә бәяләмә әзерли, мөрәҗәгать итүчене, имза салдырып, алар белән таныштыра һәм бәяләмәнең бер нөсхәсен мөрәҗәгать итүчегә тапшыра, бәяләмәнең икенче нөсхәсен личное делосына урнаштырып куя.

Башкару срогы: дәүләт хезмәтен индивидуаль күрсәтү процедурасы, мөрәҗәгать итүче билгеләнгән көнне килгәндә, 5 минут эчендә, төркемләп күрсәтү –алдагы процедура тәмамланганнан соң 15 минут эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бәяләмә бирү, бәяләмәнең икенче

нөсхәсен мөрәҗәгать итүченең личное делосына урнаштырып кую.

3.15. Административ процедураларны (гамәлләр) башкару нәтиҗәләрен халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәте алучылар регистрына кертү.

ЦЗН белгече:

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәте алучылар регистры урын алган программ-техник комплекста терки;

дәүләт хезмәте алучының личное делосын ЦЗНның агымдагы архивына тапшыра.

Башкару срогы: процедура алдагы процедура төгәлләнгәннән соң 5 минут эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: административ процедуралар нәтиҗәләрен халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәте алучылар регистрына кертү.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә контрольлек итү тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә агымдагы контрольлекне ЦЗН директоры яки вәкаләтле хезмәткәре хәл итә.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә агымдагы контрольлек бу административ регламентның, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 8 ноябрь, 2010 ел, №972н боерыгы белән расланган Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре алучылар регистрларын алып бару тәртибенең, алардагы мәгълүматларны тапшыру тәртибенең, срокларын һәм формасын кертеп, дәүләт хезмәте алучыларның учет документлары бланкларын һәм дәүләт хезмәте күрсәтү эшчәнлеген җайга салучы башка документларны тутыру, алып бару һәм саклауга карата таләпләрнең үтәлешенә тикшерүләр үткәрү юлы белән хәл ителә.

Агымдагы контрольлекне хәл итүнең вакыт аралыкларын ЦЗН директоры билгели.

4.3. Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә контрольлекне Министрлык халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт гарантияләрен, эшсез гражданнарга социаль ярдәм ягыннан дәүләт гарантияләреннән тыш, тәэмин итүгә күзәтчелек һәм контрольлек итү вәкаләтләрен үтәү кысаларында хәл итә.

Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә контрольлек Министрлык тарафыннан планлы (планнан тыш) күчмә (документар) тикшерүләр юлы белән хәл ителә.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышында кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмау) җаваплы ЦЗН белгечләре закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә җавап бирә.

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан дәүләт хезмәте күрсәтүгә контрольлек итү ЦЗН эшчәнлегенең дәүләт хезмәте

күрсәтүдәге хәбәрдарлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләр) судка кадәр карап тикшерү мөмкинлеге тудыру юлы белән хәл ителә.

**5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, шулай ук вазыйфаи затларының дәүләт хезмәте күрсәтүдәге гамәлләренә (гамәл кылмау), кабул иткән карарларына судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе**

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы ЦЗН белгечләренең гамәлләренә (гамәл кылмау) ЦЗН директорына, Министрлыкка судка кадәр тәртиптә шикаять белдерүгә хокуклы.

Дәүләт хезмәте алучылар шәхсән шикаять белән мөрәҗәгать итүгә яки язмача мөрәҗәгать, шикаять (дәгъва) җибәрергә хокуклы.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән, түбәндәге очракларда, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең запросын теркәү срогы бозылганда;

дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылганда;

мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документлар таләп ителгәндә;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, баш тартуга нигезләр федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясе башка норматив-хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актлары нигезендә күздә тотылмаганда;

дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп иткәндә;

дәүләт хезмәте күрсәтүче ЦЗН, ЦЗН белгече дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хаталарны төзәтүдән баш тартканда яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозганда.

5.3. Шикаять язмача рәвештә кәгазьдә яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта аша, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, Министрлыкның рәсми сайты (http:// mtsz.tatar.ru/), Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы: (http://uslugi.tatar.ru), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (бердәм порталы

(http://www.gosuslugi.ru) аша җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү барышында ЦЗН белгечләре тарафыннан кабул ителергә мөмкин.

5.4. Шикаятьне карап тикшерү срогы – аны теркәүгә алганнан соң унбиш эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче ЦЗН, ЦЗН белгеченең мөрәҗәгать итүчедән документларын кабул итеп алудан, яки хаталарны төзәтүдән баш тарту очрагында яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга шикаять белдерү очрагында – шикаятьне теркәүгә алганнан соң биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаять түбәндәге мәгълүматлардан торырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмау) шикаять белдерелгән дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче белгеч исеме;

2) мөрәҗәгать итүче - физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), яшәү урыны турында мәгълүматлар, мөрәҗәгать итүче – юридик затның урнашу урыны турында мәгълүматлар, шулай ук элемтәгә керү өчен телефон номеры (номерлар), электрон почта адресы (адреслар) (булганда) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки ЦЗН белгеченең шикаять белдерелгән карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмау) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, ЦЗН белгеченең карары һәм гамәле (гамәл кылмау) белән килешмәвенә дәлилләр.

5.6. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгәннәрне раслаучы документлар яки аларның күчермәләре кушып бирелергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә кушып бирелә торган документлар исемлеге китерелә.

5.7. Шикаятькә шикаять белдергән дәүләт хезмәте алучы имза сала.

5.8. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча гамәлләренә шикаять белдерелгән вазыйфаи зат түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән ЦЗН тарафыннан кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда ЦЗН тарафыннан җибәрелгән хаталарны төзәтү рәвешендә, Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актлары нигезендә түләтү күздә тотылмаган акча средстволарын мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Карар кабул ителгәннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язмача һәм электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.9. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта шикаятьләрне карап тикшерүгә вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны бер эш көне эчендә прокуратура органнарына җибәрә.

ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 14.02.2014 ел, №70 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында эшсез гражданнарга психологик ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең типовой административ регламентына №1 кушымта

**Үрнәк**

“Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ директорына

_________________________________»
*(район /шәһәр)*

_________________________________
*(директорның фамилиясе, исеме, атасының исеме)*

**Эшсез гражданинга психологик ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза**

Мин, _______________________________________________________________,
*(эшсез гражданинның фамилиясе,исеме, атасының исеме)*
түбәндәгеләргә бәйле рәвештә эшсез гражданнарга психологик ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүегезне сорыйм

_____________________________________________________________________
*(сәбәбен күрсәтергә)*
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________

“Персональ мәгълүматлар турында” 27.07.2006 ел, № 152-ФЗ Федераль закон нигезендә, бу Гариза–анкетада күрсәтелгән персональ мәгълүматларны җыюга, эшкәртүгә, шул исәптән автоматлаштырылган рәвештә, саклауга, персональ мәгълүматларны мәгълүмати алышу системасында өченче затларга тапшыруга ризалык бирәм.

"__" ______________ 20__ ел. __________________________________
*( эшсез гражданин имзасы)*

ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 14.02.2014 ел, №70 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында эшсез гражданнарга психологик ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең типовой административ регламентына №2 кушымта

**Үрнәк**

## Эшсез гражданинга психологик ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим

Дәүләт казна учреждениесе ____________________________

______________________________________________________________________

*(халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесе атамасы)*

______________________________________________________________________

эшсез гражданинга ___________________________________

*(эшсез гражданинның*

______________________________________________________________________

*фамилиясе, исеме, атасының исеме)*

эшсез гражданнарга психологик ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте алырга тәкъдим итә.

Гражданнарга кулай эш эзләүгә ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүче халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесе белгече____________________________________________________________

*(белгечнең вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме)*

______________________________________________________________________

"__" ___________ 20__ ел. ______________________________

*(белгеч имзасы)*

Тәкъдим белән таныштым, дәүләт хезмәте алу белән килешәм/килешмим *(кирәклесенең астына сызарга)*

Баш тарту сәбәбе _____________________________________________________

*(сәбәбен күрсәтергә)*

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

"Персональ мәгълүматлар турында" 27.07.2006 ел, № 152-ФЗ Федераль закон нигезендә, бу Тәкъдимдә күрсәтелгән персональ мәгълүматларны җыюга, эшкәртүгә, шул исәптән автоматлаштырылган рәвештә, саклауга, персональ мәгълүматларны мәгълүмати алышу системасында өченче затларга тапшыруга ризалык бирәм.

"__" ________ 20__ ел _______ (__________________________________________)

*( имзасы) (эшсез гражданинның фамилиясе, исеме, атасының исеме)*

ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 14.02.2014 ел, №70 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында эшсез гражданнарга психологик ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең типовой административ регламентына №3 кушымта

**Үрнәк**

**Эшсез гражданинга психологик ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмә**

Дәүләт казна учреждениесе ___________________________________________
_______________________________________________________________
*(халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесе атамасы)*
_______________________________________________________________
эшсез гражданнарга психологик ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтте
_______________________________________________________________
*(фамилиясе, исеме, атасының исеме)*
_______________________________________________________________

Нәтиҗәсе:

1. Дәүләт хезмәте тулы күләмендә күрсәтелде: әйе/ юк *(кирәклесенең астына сызарга)*
2. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге сәбәп буенча вакытыннан алда туктатылды
_______________________________________________________________
*(сәбәбен күрсәтергә)*
_______________________________________________________________
3. Тәкъдим ителде: ______________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________


Дәүләт хезмәте күрсәтүче халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесе белгече
_______________________________________________________________
*(белгечнең фамилиясе,исеме, атасының исеме)*

"__" ________ 20__ ел ________________________
*( белгеч имзасы)*

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмә белән таныштым:
"__" ______ 20__ ел ____________ (_____________________________________)
*(имзасы)/ (эшсез гражданинның фамилиясе, исеме, атасының исеме)*

ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 14.02.2014 ел, №70 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында эшсез гражданнарга психологик ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең типовой административ регламентына №н кушымта

**Дәүләт хезмәте күрсәтүдә гамәлләрнең эзлеклелегенең блок-схемасы**



Мөрәҗәгать итүче белән тест (анкета) нәтиҗәләре буенча фикер алышу һәм эшкә урнашуга, һөнәри яктан үз урынын табуга һәм карьера үсешенә комачаулый торган төп проблемаларын ачыклау (тест (анкета) үткәрелгән көнне яки дәүләт хезмәте күрсәтү графигында билгеләнгән көнне: дәүләт хезмәтен индивидуаль күрсәткәндә – 5 минут, төркемләп күрсәткәндә – 10 минут

↓

Мөрәҗәгать итүче белән психологик ярдәм юнәлешләрен килештерү, психологик консультация һәм (яки) психологик тренингны кертеп, мөрәҗәгать итүченең ачыкланган проблемаларыннан, индивидуаль үзенчәлекләреннән һәм тормыш эшчәнлегендәге чикләнүләрдән, үзе сайлар алган дәүләт хезмәте күрсәтү формасыннан чыгып (дәүләт хезмәте күрсәтү графигында билгеләнгән көнне: дәүләт хезмәтен индивидуаль күрсәткәндә – 5 минут, төркемләп күрсәткәндә – 10 минут

Мөрәҗәгать итүче белән тренинг дәресләре үткәрү (эшсез гражданин ризалыгы белән видеотренинг) һәм (яки) психоэмоциональ киеренкелекне һәм борчылу халәтен юкка чыгаруга, эш эзләү процессында килеп чыгучы авырлыкларга карата уңай мөнәсәбәт булдыру, төрле низаглы хәлләр килеп туганда үзенең проблемасын һәм үзенең ролен киңрәк аңлавын булдыру, үз-үзен тотышының яңа ысулларына өйрәтү, үз-үзен тотышында тискәре факторларны бетерүгә юнәлдерелгән психологик консультацияләр уздыру (дәүләт хезмәте күрсәтү графигында билгеләнгән көнне: дәүләт хезмәтен индивидуаль күрсәткәндә – 25 минут, төркемләп күрсәткәндә – 130 минут

↓

Тренинг дәресләре һәм (яки) психологик консультация нәтиҗәләре буенча фикер алышу (тренинг дәресләре һәм (яки) психологик консультация үткәрелгән көнне (дәүләт хезмәтен индивидуаль күрсәткәндә – 5 минут, төркемләп күрсәткәндә – 10 минут

↓

Хезмәт белән кызыксынуын арттыру, эш эзләү һәм эшкә урнашу теләген көчәйтү, эшкә урнашуга комачаулаган психологик проблемаларны юкка чыгару яки актуальлеген киметү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмә рәвешендә тәкъдимнәр әзерләү (тренинг дәресләре һәм (яки) психологик консультация үткәрелгән көнне яки дәүләт хезмәте күрсәтү графигында билгеләнгән көнне: дәүләт хезмәтен индивидуаль күрсәткәндә – 10 минут, төркемләп күрсәткәндә – 15 минут)

↓

Мөрәҗәгать итүче белән тәкъдимнәр буенча фикер алышу һәм аларны тормышка ашыру буенча эшсез гражданинның гамәлләре юнәлешләрен билгеләү (дәүләт хезмәте күрсәтү графигында билгеләнгән көнне: дәүләт хезмәтен индивидуаль күрсәткәндә – 5 минут, төркемләп күрсәткәндә – 15 минут)

↓

Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмәнең 1 нөсхәсен бирү, дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмәнең икенче нөсхәсен дәүләт хезмәте алучының личное делосына урнаштырып кую (тәкъдимнәр буенча фикер алышу үткәрелгән көнне: дәүләт хезмәтен индивидуаль күрсәткәндә – 5 минут, төркемләп күрсәткәндә – 15 минут)

↓

Административ процедураларны (гамәлләр) башкару нәтиҗәләрен халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре алучылар регистрына кертү (мөрәҗәгать итүчегә бәяләмә тапшырылган көнне: 5 минут эчендә хәл ителә)

ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 14.02.2014 ел, №70 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында эшсез гражданнарга психологик ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең типовой административ регламентына белешмә-кушымта

**Татарстан Республикасында эшсез гражданнарга психологик ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы органнар һәм вазыйфаи затлар турында мәгълүматлар**

## 1. Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре (алга таба - ЦЗН)

| Вазыйфасы атамасы | Телефоны | Урнашу урыны адресы, электрон адресы |
|---|---|---|
| ГКУ ЦЗН директоры | | |

## 2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфасы атамасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-01 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 557-20-03 | mtsz@tatar.ru |
| Һөнәргә өйрәтү һәм профориентация бүлеге начальнигы | 557-20-90 | Sofya.Tonkonog@tatar.ru |

**3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты**

| Вазыйфасы атамасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Социаль үсеш идарәсе начальнигы | 264-77-29 | pisma@tatar.ru |